РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШЛЫГЫ

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 58
факс: 8 (84346) 2-17-57

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур.58
тел: 8 (84346) 2-10-48

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 нчы елның 12 нче сентябре 57№

Әлки муниципаль районында ирекtән мәхрүм
итү урыннарыннан азат ителгән затларны
ресоциализацияләү эшчәнлеген оештыру турында

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләрен хәл итү максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 нчы елның 29 нчы июлендәге 631 номерлы карары нигезендә, Әлки муниципаль районы башлыгы КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндә бирелгәнне расларга:

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмә.

2. Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия утырышында ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми//htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И. В. Йосыповка йөкләргә.

Әлки муниципаль район Башлыгы Никошин А.Ф.

Совет Алькеевского муниципального района РТ

Расланган
Әлки муниципаль
районы Башлыгы Карары
201__ елның ___ ___________ _____№

# Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмә.

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия ( алга таба - ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башлыгы каршындагы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән үзара эшчәнлеген координацияләүне һәм аларның үзара хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итүче даими эшләүче координация органы булып тора.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерүгә ярдәм күрсәтүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем турында Нигезләмәгә таяна.

1.3. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге ресоциализациягә ярдәм итү күздә тотыла торган затларның ихтыяр белдерүләре иреклелек һәм ирек принципларына нигезләнә.

## II. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып торалар:

2.1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында иректән мәхрүм итү рәвешендәге һәм (яки) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга, шул исәптән җинаять-хокукый характердагы җинаять җәзасына дучар булган затларны җәмгыятькә рентеграцияләү максатларында социаль-икътисадый, педагогик, хокукый характердагы чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән:

пенитенциар озата бару;

һөнәри юнәлеш бирү һәм хезмәт адаптациясе;

торак һәм көнкүреш кирәк – яраклары белән тәэмин итү;

медицина ярдәме;

психологик ярдәм;

югалган туганлык һәм башка социаль элемтәләрне торгызуда булышлык күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләүнең башка формалары.

2.2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән үзара эшчәнлеген координацияләүне һәм аларның үзара хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итү.

2.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның республика регистрын алып бару.

2.4. Кабат (рецидив) җинаятьчелекне кисәтү.

2.5. Җәмәгатьчелеккә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү һәм хезмәт рентеграциясе буенча Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә алып барыла торган эш турында мәгълүмат бирү.

III. Ведомствоара комиссия вәкаләтләре

Аңа йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында ведомствоара комиссия түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

3.1. Шәхси тәртиптә ресоциальләштерүгә ярдәм күрсәтүгә ризалык биргән затларның социаль хәлен карый һәм анализлый.

3.2. Законда каралган дәүләт һәм муниципаль ярдәм механизмнарын, башка оешмаларның һәм граждан җәмгыяте институтларының мөмкинлекләрен исәпкә алып, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү буенча индивидуаль программаны эшли. Реабилитация программасында каралган һәр чараны тормышка ашыру өчен җаваплы затларны аларны тормышка ашыру вакытын билгели.

3.3. Ресоциализацияләү буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләрен һәм нәтиҗәлелеген анализлый.

3.4. Социаль ресоциянең индивидуаль программасын гамәлгә ашыруны туктату турында Карар кабул итә:

тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешелгәч;

зат даими яшәү өчен Әлки муниципаль районыннан читкә чыкканда (зат башка муниципаль районга (шәһәр округына) әлеге факт турындагы мәгълүмат булган материаллар белән бергә затка карата Татарстан Республикасы тиешле муниципаль районының ведомствоара комиссиясенә җибәрелә);

заттан ресоциализациядән баш тарту турында гариза керүе;

алга таба индивидуаль ресоциализация программасын гамәлгә ашыру мөмкинлеген юкка чыгара торган башка очракларда.

3.5. Әлки муниципаль районында кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.6. Ведомствоара комиссия хокуклы:

3.6.1. Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан үтәлешенә тәкъдим ителгән карарлар үз компетенциясе чикләрендә кабул итәргә;

3.6.2.Җинаять яки административ җаваплылык буенча закон бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен хокук саклау органнарына тиешле документлар һәм материалларны җибәрергә.

3.7. Ведомствоара комиссия үз компетенциясе кысаларында хезмәттәшлек итә:

3.7.1. иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән;

3.7.2. Эчке эшләр органнарыбелән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

индивидуаль профилактик эш үткәрү;

хокукый белемнәрне пропагандалауда катнашу;

3.7.3.Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләр (социаль яклау бүлекләре, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре) белән берлектә түбәндәге мәсьәләләр буенча:

1999 нчы елның 17 нче июлендәге 178-ФЗ номерлы "Дәүләт социаль ярдәме турында " Федераль законны һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 нче елның 2 нче сентябрендәге 635 номерлы "Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә дә, күрсәтү турында" карарын гамәлгә ашыру кысаларында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга матди ярдәм күрсәтү;

билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәт алучылар белән профилактик эш алып бару;

социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә иректән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзага хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарны, шулай ук социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль адаптацияләү чаралары;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итәргә әзерләнүче затларны хезмәт базары турында мәгълүмат бирү, вакансияләр булу юлы белән яңадан социальләштерүгә ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга , билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган затларга, эшчәнлек өлкәсен (һөнәрен) сайлап алу максатларында һөнәри юнәлеш бирү буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү), эшкә урнаштыру, һөнәри белем бирү, эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, хезмәт базарында эшсез гражданнарга социаль адаптация, һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

ирекләреннән мәхрүм итү урыннарыннан чыккан гражданнарга туры килерлек эш эзләүдә ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән эш бирүчеләрне кызыксындыру;

3.7.4. Беренчел медик-санитар ярдәм оештыру, профилактик һәм диспансер күзәтүен оештыру мәсьәләләре буенча Сәламәтлек саклау территориаль идарәсе, сәламәтлек саклау учреждениеләре белән;

3.7.5. Компетенциясе нигезендә дәүләт хакимиятенең бүтән органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары белән.

## IV. Ведомствоара комиссияне формалаштыру тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында формалаша.

Ведомствоара комиссия рәисе:

Ведомствоара комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

Ведомствоара комиссия утырышларын алып бара, хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия;

Ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына үз вәкаләтләре кысаларында йөкләмәләр бирә;

Ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән документларга кул куя;

Ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Ведомствоара комиссия сәркатибе:

Ведомствоара комиссия рәисе күрсәтмәләрен үти;

Ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга ведомствоара комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнарына җәза үтәү системасы учреждениеләре администрацияләреннән керә торган мәгълүматны җыюны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра; алда торган затны азат итү, аның торагы, эшкә яраклылыгы һәм булган белгечлекләре турында мәгълүмат җыя һәм гомумиләштерә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализациягә ярдәм итү турында гаризалар кабул итә;

ресоциализация программасының һәр катнашучысына ресоциализацияләүнең индивидуаль программасы чараларын үтәү буенча документлар һәм белешмәләр кертеләгән озату картасын һәм шәхси эшне рәсмиләштерә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның республика регистрының муниципаль сегментын алып бара;

Ведомствоара комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан соратып ала;

Ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

утырыш нәтиҗәләре мәгълүматлары буенча Ведомствоара комиссия рәисе күрсәтмәләрен үтәүне оештыра;

Ведомствоара комиссия функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы халкына мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районы башлыгы боерыгы белән раслана.

4.3. Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, мәгариф оешмалары (килешү буенча)вәкилләре керә ала.

4.4. Ведомствоара комиссия составына элек иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, ресоциализацияләүнең уңай тәҗрибәсе булган затлар да кертелергә мөмкин.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышларында Әлки районы прокуратурасы вәкиле дә катнашырга хокуклы (килешү буенча).

4.6. Ведомствоара комиссия утырышына Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының ведомствоара комиссия составына кермәгән дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырыла ала.

4.7. Ведомствоара комиссия эшендә катнашу җәмәгать башлангычларында башкарыла.

## V. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эше даими нигездә алып барыла.

5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализациягә ярдәм итү турында гаризалар, ләкин айга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә, керүгә карап үткәрелә. Кирәк булган очракта, ведомствоара комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук ведомствоара комиссия әгъзасы (рәис белән килештереп һәм ведомствоара комиссия секретаре тәкъдиме буенча) инициативасы буенча Ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.3. Ведомствоара комиссия утырышын ведомствоара комиссия рәисе, ә ул булмаганда яки аның кушуы буенча – ведомствоара комиссия рәисе урынбасары алып бара.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышы вакыты һәм урыны турында ресоциализацияләүгә ярдәм күрсәтү турында гариза бирүчеләргә, аларның туганнарына, утырышларда катнашу максатка яраклы дип табылган башка затларга хәбәр ителә.

5.5. Ведомствоара комиссия утырышы вакыты һәм урыны турында Әлки районы прокуроры хәбәр ителә.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы, составының яртысыннан артыгы катнашу шарты белән, вәкаләтле булып тора.

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары тәкъдим итү характерына ия һәм утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.8. Ведомствоара комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр турында фикер алышканда тигез хокукларга ия.

5.9. Мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән зат теләге буенчаутырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча үткәрелә.

5.10. Ведомствоара комиссия әгъзалары комиссия утырышында тикшерелгән мәсьәләләр турында мәгълүматларны әлеге мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка таратырга хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматларны тараткан өчен ведомствоара комиссия әгъзалары закон нигезендә җаваплы.

5.11. Ведомствоара комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатында, ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат бирү рөхсәт ителә.